ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз икенче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз икенче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзаларын билгеләп кую турында.
3. Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсен Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты итеп үзгәртү турында Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимен килештерү турында.
4. Вәлиев Альберт Шәфкать улын Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе урынбасары вазыйфасына билгеләп кую турында.
5. “2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 388-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. “Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында” 387-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
7. “2018 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары үзенчәлекләрен чагылдыра торган региональ коэффициентны билгеләү турында” 381-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
8. “Пенсиягә федераль социаль өстәмә күләмен билгеләү өчен Татарстан Республикасында 2018 елга пенсионерның яшәү минимумы күләмен билгеләү турында” 380-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
9. “Нурлат муниципаль районының “Нурлат шәһәре” һәм “Яңа Иглай авыл җирлеге” муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм “Нурлат муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең һәм аның

составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 370-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 377-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. "Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 385-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

12. "Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 15 һәм 33 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында" 376-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. "Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында" Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 378-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. "Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 382-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. "Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы турында" 375-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

16. "Татарстан Республикасында гражданнарның эконом классլы торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 372-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

17. "Татарстан Республикасы Җир кодексының 9 статьясына үзгәреш кертү турында" 379-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

18. "Мәгариф турында" Татарстан Республикасы Законының 21 статьясына үзгәреш кертү хакында" 373-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

19. "2018 елга Татарстан Республикасында муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында" 384-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

20. "2018 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт

гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында” 386-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

21. “Әйләнә-тирә мохитне саклау турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында” федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

22. “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 28 статьясына үзгәреш кертү хакында” федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

23. “Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Киров өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында.

24. “Җир асты байлыклары турында” Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында” федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Магадан өлкә Думасының закон чыгару инициативасы турында.

25. “Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында” федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ставрополь крае Думасының закон чыгару инициативасы хакында.

26. “Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында” 228841-7 номерлы федераль закон проекты хакында (транспорт салымын, җир салымын һәм физик затлар мөлкәтенә салым түләү срокларын күчерү өлешендә).

27. “Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның гомуми принциплары һәм аларның эшчәнлеге турында” Федераль законның 9 статьясына үзгәреш кертү хакында” 241665-7 номерлы федераль закон проекты турында (контроль-хисап органнары тарафыннан Россия Федерациясе субъекты дәүләт программалары проектларына финанс-икътисадый экспертиза уздыру хакында).

28. “Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 23.3 һәм 28.3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында” 223931-7 номерлы федераль закон проекты турында (эчке эшләр органнарының (полициянең) вазыйфаи затлары вәкаләтләрен төгәлләштерү өлешендә).

29. “Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 9.5 һәм 19.5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында”

114011-7 номерлы федераль закон проекты турында (административ җаваплылыкны көчәйтү өлешендә).

30. “Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына порошоксыман спиртлы продукция җитештергән һәм (яисә) әйләнештә йөрткән өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында” 261263-7 номерлы федераль закон проекты турында.

31. Төрлесеннән: Татарстан Республикасында җәмәгать судьялары эшчәнлеге турында мәгълүмат.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2017 елның 21 сентябре
№ 1920-V ДС